**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**15.10.2018** г. Казань **№ 127 од**

Татарстан Республикасы юстиция министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында Татарстан Республикасы юстиция министрлыгының 2015 елның 10 декабрендәге 01-02/798 номерлы боерыгы белән расланган нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Министрлык, дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы типлаштырылган нигезләмәгә үзгәреш кертелүгә бәйле рәвештә, **боерам:**

Татарстан Республикасы юстиция министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында Татарстан Республикасы юстиция министрлыгының 2015 елның 10 декабрендәге 01-02/798 номерлы боерыгы белән расланган нигезләмәгә (2017 елның 7 ноябрендәге 01-02/137 номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12. Иҗтимагый совет карары белән Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый совет тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүматлар һәм бәяләмәләр бирү өчен башкарма органнар, коммерцияле булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар, башка белгечләр һәм гражданнар чакырылырга мөмкин.

Массакүләм мәгълүмат чараларының Иҗтимагый совет әгъзалары булып тормаган әгъзалары Иҗтимагый совет утырышларында Иҗтимагый совет чакыруы буенча катнаша алалар.».

Министр Р.И. Заһидуллин